Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты.

**КАРАР**

№ 2 2024 елның 31 гыйнвары.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2024 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 23.01.2024 ел, №46 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге карар бирә:

1. 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 8370,20 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә), шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Аксубай муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы мәгълүмати сайты (http://aksubayevo.tatarstan.ru) "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Х.Кәбиров

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның "31" гыйнварындагы
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
2024 елның 1 февраленнән.

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4170,20 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1000 |
| 4. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3200 |
| Барлыгы | **8370,20** |

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның "31" гыйнварындагы 2
номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
2024 елның 1 февраленнән.

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.Кәфенләү | 500 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3670,20 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1000 |
| 5. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3200 |
| Барлыгы | **8370,20** |